**Республика Татарстан**
**Палата имущественных и земельных отношений Заинского муниципального района**

ул.Автозаводская, д.1 А,
г.Заинск, Республика
Татарстан 423520
тел. 8(85558)2-80-31,
2-80-32,2-80-33, 2-80-34
E-mail: Pzio.Zainsk@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы**

Автозавод урамы, 1 а йорт,
Зәй шәһәре Татарстан
Республикасы, 423520
тел. 8(85558)2-80-31,
2-80-32,2-80-33, 2-80-34
E-mail: Pzio.Zainsk@tatar.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**«28» 12 2024ел.** **№ 1055П**

**«Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» карарына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы турында нигезләмә белән

**боерык бирә:**

1. Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта нигезендә расларга.
2. Зәй муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасының 2021 елның 13 августындагы 620П номерлы «Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерык үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының җир мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы Т.Н. Кузнецовага йөкләргә.

**Палата рәисе** **Р.Р. Шәйхиев**

Юрисконсульт